**СОВЕТ ДЕРЖАВИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422620,Татарстан, с. Державино,
ул. Заббарова, д.39
тел: 3-45-20

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДЕРЖАВИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422620 Державино авылы,
Заббаров урамы, 39 нчы йорт,
тел: 3-45-2

---

**2024 елның 8 ноябре** **59 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Державино авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 10 апрелендәге 5 номерлы Державино авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ««Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 маендагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Державино авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:
:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Державино авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 10 апрелендәге 5 номерлы Державино авыл җирлеге Советы карарына (10.05.2018 № 8, 29.10.2018 № 24, 28.10.2020 № 18, 02.12.2022 № 44-1, 02.12.2022 № 44-2, 16.01.2023 № 1-1, 05.06.2024 №31 Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлеге Советы карарларына кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктта "13 323" саннарын "13 990" саннары белән алыштырырга;

күрсәтелгән карарның 2 нче кушымтасын яңа редакциядә (кушымта)бәян итәргә.

1. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә туны муниципаль районның Державино авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисади үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Державино**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **И.И.Камалиева**

Татарстан Республикасы муниципаль районының
Державино авыл җирлеге Советының 2018 елның
12 апрелендәге 5номерлы карарына 1нче кушымта
*(ТатарстанРеспубликасы муниципаль районының*
*2024 елның 8 ноябрендәге 59 номерлы Державино*
*авыл җирлеге Советы карары редакциясендә)*

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмен исәпләгәндә кулланыла торган тапкырлык коэффициентлары

| Вазыйфаның исеме | Тугызынчы төркем <*> | Унынчы төркем <*> | Унберенче төркем <*> | Уникенче төркем <*> |
|---|---|---|---|---|
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 26 029 | 22 810 | 20 991 | 19 173 |

<*> Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы

карары белән расланган, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы чыгымнарын формалаштыру нормативларының 1 пункты нигезендә муниципаль берәмлек кергән хезмәт өчен түләү төркеме.

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хакы күләмен билгеләү максатыннан тиешле муниципаль берәмлек статусына һәм аның территориясендә даими яшәүче халык санына карап түбәндәге хезмәт хакы төркемнәре буенча бүленә:

1) шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә барлыкка килгән авыл һәм шәһәр торак пунктлары:

тугызынчы төркем 10 меңнән артык кеше яшәгән муниципаль берәмлекләр;

унынчы төркем - халык саны 5 меңнән 10 меңгә кадәр булган муниципаль берәмлекләр;

унберенче төркем - 1,5 меңнән 5 меңгә кадәр кеше яшәгән муниципаль берәмлекләр;

уникенче - төркем халык саны 1,5 мең кешегә кадәр булган муниципаль берәмлекләр.

.